| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

| | | |
|---|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Иске Әлмәт ав. | КАРАР |

«13» ноябрь 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча: Лесная урамында урнашкан мәчет янында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселокның Урман урамындагы йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлегендә халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселок территориясендә теркәлү урыны буенча яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 13 000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселок территориясен төзекләндерү.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселок мәчете территориясе тирәсен тотып алу;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселокның буасы аша кичү юлын реконструкцияләү.
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселокның буалары территориясен планлаштыру һәм төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru/rus/st_almetevskoe.htm/, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселок, Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Хисамов Р.Г.